2. Дагбаева Н.Ж. Экологическая школа для устойчивого развития местного сообщества //Педагогика. - 2004. - №3. - С.40-44.
3. Гайсин И.Т. Преемственность системы непрерывного экологического образования. Дисс. доктора пед. наук. -Казань,КГПУ, 2000. - 408с.
4. Ясвин В.А. Экспертиза школьной образовательной среды. М., 2000.
5. Подробности: http://repository.kpfu.ru/?p_id=52157
6. Теплов Д.Л. Экологическое воспитание школьников в процессе дополнительного образования. Дисс. доктора пед. наук. - Москва, МГПУ им.М.А. Шолохова, 2005. -431с.
7. Гайсин И.Т. Роль учреждений дополнительного образования в экологическом воспитании учащихся. Статья// Единство учебной, внеурочной и внешкольной деятельности в современной школе: Материалы регион. научно-практич. семинара (13 декабря 2011 г.). " Казань: Изд-во МОиН РТ, 2011. - С.4-10.
URL:http://repository.kpfu.ru/?p_id=52157
8. Сайт Городского детского эколого-биологического центра г. Казани URL:https://edu.tatar.ru/sovetcki/page2454.htm/page2455.htm (дата обращения: 17.02.2015)

Чишмәләр чыңы

Садыков Рәвил Хәсән улы, Садыкова Зөһрә Зәкәрья кызы,
Казан шәһәре Идел буе районынның 18нче татар гимназиясенеңюгары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары

Аннотация. Мәкаләдә экологик тәрбиянең бер юнәлеше буларак чишмәләрне тергезү һәм саклау проблемасы күтәрелә.

Ключевые слова. Төп сүзләр: чишмә, чишмәләр тарихы, экологик тәрбия, чишмәләрнең файдасы.

Abstract. In article the problem of revival and preservation of springs as one of the directions of ecological education rises.
Keywords: spring, history of springs, ecological education, purpose of springs.

Без, кешеләр – табигать балалары. Табигатьнең җылысы, саф һавасы, эчәр сулары безгә яшәү яме бирә, безне үстерә, көчле итә.

Табигать – зур көчкә ия
Аны кирәк , тоеп аңларга
Аның матурлыгын югалтмыйча
Нык сакларга, сөеп саннарга

Табигатьнең мондый матурлыгы
Кешеләргә, һәрчак, көч бирә;
Аны аңлый белгән кешеләрне –
Канатлата, бик нык үстерә

Һәр фасылы – матурлыгын бирә
Һәм байлыгын – күрә белгәнгә,
Борынгыдан аны зурлаганнар
Мактаганнар – төрле телләрдә. (Р.Х.Садыков)

Әйе, табигатьне ярату, саклау, чиста тоту – бүгенге заман өчен – бик актуаль булган юнәлеш. Шуңа да, үсеп килүче яшь буынга экология тәрбиясе бирү бик мөһим һәм кирәкле. Табигатьнең матурлыгын күрә, тоя белү бик күп нәрсәгә төшендерә. Агачлар, үсемлекләр белән танышу, кечкенә бөҗәкләрнең дә файдасы һәм зарарлы якларын ачыкларга өйрәтү – үзе кирәкле эш. Авыл тирәсендәге чишмәләр тарихын белү, алар турында төрле риваятьләр ишетү дә табигатькә якынайта. Чишмәләрнең челтерәп аккан суларын уч тутырып эчү никадәр көч, сихәт бирә! Челтерәп аккан су тамчылары нидер сөйли кебек.

Бу чишмәнең – үз сере бар

Исемендә – җисеме,
Оркыя ул – Мөхәммәтнең
Иң чибәр кыз исеме.

Бу исем ул гарәпчәдән-
Тылсым, сихерне ача;
Шуңа күрә дә үзенә –
Күңелләрне бик тарта.

Тылсымлы чишмә сулары –
Саулык, тынычлык бирә;
Аның суын авыз иткән –
Һәрвакыт суга килә.

Хәзерге вакытта авылларда чишмәләрне тергезүгә зур игътибар бирелә. Һәр инешнең башы чишмә бит.Әздән зур су җыела. Шуңа күрә, укучыларга чишмәләргә багышлап язылган шигырьләр уку файдалы. Чөнки бу шигырьләр авыл тарихын ача, экологик тәрбия бирә.

Чишмә – матур тау астыннан
Агып ята көнчыгыштан,
Бик күп еллар аның суын
Алан кызлары ташыган

Суы тәмле һәм файдалы
Ашкынып ул – шаулап ага,
Аның суын эчкән һәркем –
Гел ашкына аңа таба.

Көчле матур тавышы белән
Ул күпләрне куандырган,

Аңа лаеклы исем дә
“Шалтырама” – дип кушылган.

Күп еллар тынычлап яткач
Аны кабат уяттылар ,
Тирә-якларын чистартып
Калайдан түбә яптылар.

Мондый изге эш башкарган
Рәхмәтле без һәркемгә дә,
Чишмә суын эчеп узса –
Рәхәт яшәр бар бәндә дә. (Р.Х. Садыков)

Табигать ул байлык кына түгел, ә ул матурлык, гүзәллек дөньясы. Табигатьтэге матурлыкны күрергә, ишетергә, тоярга һәм, шул рәвешчә аны кызгану, аңа сак карау кебек хисләр дә балаларда тудырырга тиешбез.

Яшьләр табигатьне күңеле белән ничек тоярга өйрәнсә, киләчәгебез дә шулкадәр ышанычлы булыр.

Кул пычранса су белән юарсың,
Су пычранса ни белән юарсың.

Көянтәле кызларыбыз иелеп су алырлык, дәү әниләребез чишмә суы белән сөтле чәй эчәрлек чишмәләребез булсын, күмелгәннәре кабат яңартылсын иде.

Туган авылым Алан – бик матур
Чишмәләре дә күп авылның,
Чорнап алган таулар итәге –
Юлын каплап тора давылның.
Һәр чишмәнең бар үз исеме
Тарихы да шунда чагыла,
Көмеш кебек чиста сулары –

Мишә елгасына агыла.

“Чакрак” тавы чишмә сулары

Дәва биреп, искә төшәләр;

Анының суын эчкән кешеләр –

Авырмыйча, таза үсәләр.

Хәтер чишмәсенең суы да

Хәтерләтә яшьлек елларны

Якын узган Сабан туйларын –

Яшьлектәге моңлы җырларны.

“Лагерь чишмәсе “нә килгәндә

“Пионер лагерь” – бары әйтемдә,

Анда алган белем, тәрбия –

Калды бик тә матур хәтердә. (Р.Х.Садыков)

Җир анага тирән ихтирам хисләрен уятырга, җирне экологик һәлакәттән коткарып калырга без яңа буын тәрбияләп устерергә тиешбез.

Без аларга :

Саклагыз сез туган табигатьне,

Тез чүгегез изге бу җиргә

Таптап изсә барысын, мыскылласа

Нигә кирәк кеше бу җирдә?!

Табигать бетсә әгәр дә,

Кешелек тә бит бетә,

Шуңа күрә уйлан ныклап,

Алда сине ни көтә?

Игра-путешествие «Мы –друзья природы» как форма экологического воспитания младших школьников

Хуснутдинова Р.Ф., МБОУ «Гимназия №18 с татарским языком обучения» Приволжского района г. Казани

Аннотация. В статье рассматриваются предметные, метапредметные и личностные результаты младших школьников в контексте развития их